КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1062

Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

Яңа ел бәйрәме чараларын үткәрүнең, гражданнар гомере һәм сәламәтлегенең, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге ФЗ-69 нчы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 20 декабреннән 2020 елның 10 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда түбәндәге чикләрдә урнашкан территорияләрдә 1 – 3 класслы куркынычы булган пиротехник эшләнмәләрдән (Бенгалия утлары, шапылдаткычлардан тыш) файдалануны тыю:

сәнәгать, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линияле) объектлары чикләреннән 500 метр;

торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, халык күп була торган объектлар, автомобиль юллары чикләреннән 50 метр.

3. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда 50 һәм 500 метр ераклыктагы зоналарда пиротехник эшләнмәләрдән файдалану тыелган объектлар исемлеген (карарга теркәлә) расларга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бу карар белән расланган исемлеккә кертелмәгән өстәмә объектларны билгеләүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә Яңа ел бәйрәме чараларын әзерләгән һәм үткәргән чорда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга;

Яңа ел бәйрәме чараларын үткәрү урыннарын Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе белән килештерергә;

Яңа ел бәйрәме чараларын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны янгын сүндерү-техник минимум программалары буенча укытуны оештырырга;

Яңа ел бәйрәме чараларын үткәргән чорда кизү торучы персонал санын арттырырга;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең ябык урыннарында ут чыгара торган пиротехник эшләнмәләрне саклауга һәм куллануга юл куймаска.

6. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

2020 елның 15 декабренә кадәр Яңа ел бәйрәме көннәрендә янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү турында белешмәлек эшләргә;

Яңа ел бәйрәме көннәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга.

7. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын үткәрү урыннарын исәпкә алуны;

балалар катнаша торган Яңа ел һәм Раштуа тамашаларын үткәрү объектларына һәм урыннарына профилактика тикшерүләре үткәрүне;

балаларның ял итү объектларында (туристлык һәм спорт базаларында, ял йортларында, шифаханәләрдә, пансионатларда, ел әйләнәсе эшли торган савыктыру лагерьларында һ.б.) профилактика тикшерүләре үткәрүне;

пиротехник эшләнмәләрне саклау һәм сату урыннарында профилактика эшен үткәрүне;

бәйрәм чаралары үткәрү объектларының хезмәт күрсәтүче персоналына янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструктажлар һәм янгын чыккан очракта эш итү күнекмәләренә өйрәнүләр үткәрүне;

бәйрәм чаралары үткәрү объектларында янгын сүндерү планнарына һәм карточкаларына төзәтмәләр кертүне, шулай ук әлеге объектларда янгынга каршы су чыганакларын тикшерүне оештыруны;

сату өчен билгеләнмәгән урыннарда пиротехник эшләнмәләр сатуны ачыклау һәм туктату буенча рейдлар оештыруны һәм аларны полиция хезмәткәрләре белән бергәләп үткәрүне.

8. Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә милли гвардия гаскәрләре бүлекчәләренең көчләрен һәм чараларын хезмәткәрләр (хәрби хезмәткәрләр) патрульлек итү маршрутларында хезмәт иткәндә янгын чыгу очракларын ачыклауга, кешеләрне коткару буенча кичекмәстән чаралар күрүгә, зыян күрүчеләргә табибка кадәр беренче ярдәм күрсәтүгә һәм янгын сүндерү формированиеләре килгәнгә кадәр янгын учакларын беренчел (кул астындагы) янгын сүндерү чаралары белән локальләштерүгә юнәлдерергә тәкъдим итәргә.

9. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итүне;

халык, юридик затлар (шул исәптән пиротехник эшләнмәләрне ваклап сатуны гамәлгә ашыручы) арасында бу карарны, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өлешендә аңлату эшен үткәрүне оештыруны;

2020 елның 10 декабренә кадәр гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияләр утырышларында Яңа ел бәйрәме чаралары үткәрелә торган урыннарда янгын куркынычсызлыгы торышы мәсьәләләрен карауны;

ирекле һәм муниципаль янгыннан саклау хезмәте әгъзаларының янгын сүндерү техникасы белән тәүлек буе кизүен оештыру чаралары комплексын гамәлгә ашыруны;

оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның Яңа ел бәйрәме чараларына һәм түбән температуралы чорга әзерлеге турындагы мәсьәләләрне тикшерүне;

тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру чаралары комплексын гамәлгә ашыруны, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларын ремонтлауны, су алу башняларын елның кышкы чорында су алу җайланмалары, табигый сулыкларны катмый торган бәкеләр белән тәэмин итүне, су чыганакларына керү юлларын кардан чистартуны оештыруны;

янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары янында шәхси автотранспорт куеп торырга ярамау турында халыкка мәгълүмат җиткерүне, кирәк булганда янгын сүндерү автомобильләренә су белән тәэмин итү чыганакларына керергә комачаулый торган автотранспортны эвакуацияләүне оештыруны;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә караган күзәтчелек эшчәнлеге территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештереп, пиротехник эшләнмәләрне сату урыннарында куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

пиротехник эшләнмәләрне саклау һәм сату шартларын мониторинглау буенча комиссияләр төзүне;

урамнардагы чыршыларны бизәү өчен сертификатлы электр гирляндаларыннан файдалануны;

пиротехник эшләнмәләрдән файдаланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештыруны;

янгынга бәйле хәлләр катлауланган очракта, тиешле территорияләрдә пиротехник эшләнмәләрне куллануны тыюны;

2020 елның 20 декабренә кадәр һәр торак пунктта янгын сүндерүнең беренчел чаралары белән тәэмин ителгән пиротехник эшләнмәләрне куллану урыннарын билгеләүне, алардан файдалануны, шул исәптән «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы ТРЗ-3 номерлы Татарстан Республикасы Законы үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итүне һәм бу турыда халыкка хәбәр итүне;

2021 елның 2 гыйнварыннан 10 гыйнварына кадәрге чорда торак йортларда гражданнар белән профилактика әңгәмәләре үткәрүне оештыру максаты белән, Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре, ирекле янгыннан саклау хезмәте әгъзалары, полиция, торак-коммуналь инспекция хезмәткәрләре, халыкны социаль яклау идарәләре (бүлекләре) хезмәткәрләре арасыннан профилактика төркемнәрен оештыруны һәм шул ук вакытта күпбалалы, имин булмаган гаиләләр, ялгыз карт гражданнар яшәгән урыннарга аеруча игътибар бирүне.

10. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

пиротехник эшләнмәләрне җитештерү, саклау һәм сату белән шөгыльләнүче юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итүне;

автомобильләргә ягулык салу станцияләрен һәм комплексларын эксплуатацияләүче юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә, алда әйтелгән объектлар территорияләрен һәм биналарын бизәгәндә, шартлаудан таләп ителә торган дәрәҗәдә якланмаган электр гирляндаларыннан һәм башка иллюминациядән файдалануга юл куймауны;

Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләренә законнарда билгеләнгән тиешле сертификатлары (яраклылык декларацияләре) булмаган пиротехник эшләнмәләрне һәм электр гирляндаларын, шулай ук аларга тутырылган техник документларда әйберләрнең янып китү үзенчәлекләре һәм алар белән эш иткәндә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән Яңа ел уенчыклары, ясалма чыршылар сатуга юл куймау чараларын күрүне;

үз балансларында тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары булган предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрүне, шул исәптән янгын сүндерү автомобильләренең су чыганакларына керә алу мөмкинлеген тәэмин итүне, шулай ук су чыганакларын кардан һәм боздан үз вакытында чистартып торуны;

гражданнарга кичектергесез оператив хезмәтләрнең «112», «01», «02» телефоннары буенча, шулай ук башка мөмкин булган ысуллар белән пиротехник

эшләнмәләрне санкциядән башка куллану очраклары турында дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына хәбәр итүне.

11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Яңа ел бәйрәмнәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

12. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 ноябрь, 1062 нче карары белән расланды

Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда
50 һәм 500 метрлы ераклыктагы зоналарда пиротехник эшләнмәләрдән файдалану тыелган объектлар
исемлеге

1. Сәнәгать объектлары:
химия объектлары һәм производстволары:
металлургия, машина төзелеше һәм металл эшкәртү объектлары һәм производстволары;
руда һәм руда булмаган казылмалар чыгару оешмалары;
төзелеш сәнәгате оешмалары;
агач эшкәртү оешмалары;
туку сәнәгать объектлары һәм җиңел сәнәгать производстволары;
хайваннар продуктларын эшкәртү оешмалары;
азык-төлек продуктларын һәм тәмләткеч матдәләр эшкәртү буенча сәнәгать объектлары һәм производстволары;
минераль ягулык яндырганда электр һәм җылылык энергиясен җитештерү оешмалары;
микробиология сәнәгате оешмалары.
2. Транспорт инфраструктурасы объектлары:
вокзаллар, метрополитен, елга портлары, аэродромнар, аэропортлар;
элемтә системалары, транспорт чаралары хәрәкәте навигациясе һәм алар белән идарә итү объектлары.
3. Ягулык-энергетика комплексы объектлары:
электр энергетикасы, нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть химиясе, газ, күмер, сланец һәм торф сәнәгате объектлары;
нефть продуктлары белән тәэмин итү, җылылык һәм газ белән тәэмин итү объектлары;
ягулык-энергетика комплексы линия объектлары (электр челтәрләре, магистраль газүткәргечләр, нефть үткәргечләр һәм нефть продуктлары үткәргечләр).
4. Торак-коммуналь хуҗалык объектлары:
торак фонды, кунакханәләр, тулай тораклар;
торак-коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен каралган оешмалар;
халыкны газ, җылылык һәм электр белән тәэмин итү объектлары.

5. Авыл хуҗалыгы объектлары:

хайваннар тоткан хуҗалыклар (дуңгыз абзарлары, сыер абзарлары, хайваннар үстерү урыннары, ат абзарлары, җәнлек фермалары);

кошчылык фермалары;

теплица һәм парник хуҗалыклары;

җиләк-җимешләр, яшелчәләр, бәрәңге, ашлык саклау урыннары;

ит, сөт эшкәртү, икмәк һәм икмәк-күмәч ризыклары җитештерү предприятиеләре һәм цехлары;

агулы химикатлар һәм минераль ашламалар саклау складлары;

орлыклар эшкәртү һәм агулау производстволары;

сыекландырылган аммиак складлары;

мал азыклары әзерләү цехлары, азык-төлек калдыкларын куллануны кертеп;

йөк автомобильләрен һәм авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау, технологик хезмәт күрсәтү һәм саклау гаражлары һәм парклары;

материаллар складлары.

6. Халык күп була торган объектлар:

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының административ биналары;

мәдәният, спорт, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, җәмәгать туклануы объектлары;

сәүдә-күңел ачу һәм офис үзәкләре.